**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 8 октябрь № 730

г. Казань

«Профессиональ компетенцияләр үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасын гамәлгә кую турында

Татарстан Республикасында «Яшь профессионаллар» (Ворлдскиллс Россия) хәрәкәтен үстерү, Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының белем бирү практикасына «Ворлдскиллс» стандартларын кертү, «Ворлдскиллс» стандартлары буенча төрле дәрәҗәдәге чемпионатларга Татарстан Республикасыннан катнашучыларны әзерләү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Профессиональ компетенцияләр үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасын (алга таба – Автоном оешма) гамәлгә куярга.

2. «Профессиональ компетенцияләр үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы уставын (карарга теркәлә) расларга.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

законнарда билгеләнгән тәртиптә Автоном оешманы дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

Автоном оешманы төзүгә бәйле башка чаралар үткәрергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 8 октябрь, 730 нчы
карары белән расланды

«Профессиональ компетенцияләр үстерү үзәге»
автоном коммерциячел булмаган оешмасы
УСТАВЫ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Профессиональ компетенцияләр үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы (алга таба – Автоном оешма), Татарстан Республикасында «Яшь профессионаллар» (Ворлдскиллс Россия) хәрәкәтен үстерү, Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының белем бирү практикасына «Ворлдскиллс» стандартларын кертү, «Ворлдскиллс» стандартлары буенча төрле дәрәҗәдәге чемпионатларга Татарстан Республикасыннан катнашучыларны әзерләү, Татарстан Республикасында һөнәри берләшмәләрне төзү һәм үстерү, «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә төрле чаралар оештыру максатларында, гамәлгә куючының ирекле мөлкәт кертемнәре нигезендә гамәлгә куелган, әгъзалыгы булмаган унитар коммерциячел булмаган оешма булып тора.

Автоном оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен һәм функцияләрен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы башкара.

1.2. Автоном оешма үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, мәгариф, социаль, мәдәни һәм бүтән чаралар (алга таба – Чаралар) әзерләү һәм үткәрүне җайга сала торган башка норматив хокукый актлар, оештыручысы Автоном оешма булган бүтән чараларны үткәрү хокуклары бирелгән оешмалар тарафыннан куелган таләпләр (алга таба – Таләпләр), Чаралар үткәрүгә мөнәсәбәтле төзелгән шартнамәләр һәм килешүләр һәм әлеге Устав нигезендә эш итә.

1.3. Автоном оешманың рус телендәге тулы исеме – автономная некоммерческая организация «Центр развития профессиональных компетенций».

Автоном оешманың татар телендәге тулы исеме – «Профессиональ компетенцияләр үстерү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы.

Автоном оешманың инглиз телендәге тулы исеме – Autonomous Nonprofit Organisation «Center for Professional Competences Development».

1.4. Рус телендә кыскартылган исеме – АНО «ЦРПК».

Татар телендә кыскартылган исеме – «ПКҮҮ» АКБО.

Инглиз телендә кыскартылган исеме – ANO «CPCD».

1.5. Автоном оешма урнашкан урынның адресы: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Дзержинский ур., 3 нче йорт.

1.6. Автоном оешма, законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынган вакыттан башлап, юридик зат булып тора, ул милкендә яки Россия Федерациясе законнары нигезендә башка хокукта аерымланган мөлкәткә ия булырга, Россия Фе-

дерациясе территориясендәге һәм аның территориясеннән читтәге банкларда счетлар ачырга хокуклы, аның үз атамасы язылган мөһере була, ул үз атамасы язылган штамплар һәм бланкларга, шулай ук билгеләнгән тәртиптә теркәлгән товар билгеләренә ия булырга хокуклы.

1.7. Автоном оешма үз исеменнән мөлкәт хокуклары һәм мөлкәти булмаган хокуклар алырга һәм гамәлгә ашырырга, вазыйфалар башкарырга, судта дәгъвачы һәм җавапчы булырга хокуклы.

1.8. Гамәлгә куючы Автоном оешманың бурычлары буенча җаваплы түгел, ә Автоном оешма үзенең гамәлгә куючысы бурычлары буенча җавап бирми.

1.9. Автоном оешма гамәлгә куючы карары нигезендә фондка үзгәртеп оештырыла ала.

1.10. Автоном оешма, Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, Россия Федерациясе территориясендә юридик затлар булмаган филиаллар төзергә һәм вәкиллекләр ачырга хокуклы.

1.11. Коммерциячел булмаган оешма буларак, Автоном оешма табыш алуны үз эшчәнлегенең төп максаты итеп куймый.

1.12. Автоном оешма мөлкәттән әлеге Уставта билгеләнгән максатларда файдалана. Автоном оешма, эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен, хуҗалык ширкәтләре оештырып яки аларда катнашып, ул төзелгән максатларга ирешү өчен кирәкле һәм әлеге максатларга туры килә торган эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә хокуклы.

Автоном оешма ул төзелгән максатларга ирешергә ярдәм иткәндә һәм әлеге максатларга туры килгәндә генә табыш китерә торган эшчәнлекне гамәлгә ашырырга хокуклы.

1.13. Әлеге Уставта каралган максатларга ирешү өчен, Автоном оешма түбәндәгеләргә хокуклы:

эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен, хуҗалык ширкәте оештырырга яки мондый ширкәттә катнашырга;

башка коммерциячел булмаган оешмалар төзергә һәм ассоциацияләргә һәм берлекләргә керергә;

билгеләнгән тәртиптә халыкара хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга, шул исәптән халыкара программаларда һәм килешүләрдә катнашырга.

## 2. Автоном оешма эшчәнлегенең максатлары һәм предметы

2.1. Автоном оешманы төзү һәм аның эшчәнлеге максатлары түбәндәгеләр: Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы икътисадын югары квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү өчен, WorldSkills International халыкара оешмасы (алга таба – WSI) стандартлары нигезендә һөнәри белем бирүне үстерү, Россия Федерациясенең социаль-икътисадый һәм мәдәни үсешендә һөнәри әзерлекнең ролен арттыру.

2.2. Әлеге Уставның 2.1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен, Автоном оешма түбәндәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыра:

2.2.1. Һөнәри осталык буенча чемпионатлар әзерләү һәм үткәрү;

2.2.2. Россия оешмаларында, шул исәптән «Ворлдскиллс Россия» һөнәри берләшмәләрне һәм эшче кадрларны үстерү агентлыгы» (алга таба – WSR)

берлегендә әгъзалык;

2.2.3. Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында һөнәри күнекмәләр дәрәҗәсен күтәрүгә, компетенцияләрне, һөнәри стандартларны һәм дәүләт белем бирү стандартларын үстерүгә булышлык күрсәтү;

2.2.4. Россия Федерациясе законнары нигезендә югары технологияле эш урыннарын булдыруны тәэмин иткән норматив хокукый актлар һәм регламент документлары төзүдә катнашу;

2.2.5. Һөнәри белем бирү стандартларын Россия Федерациясе икътисадының барлык тармакларында иң яхшы дөньякүләм практикаларына яраштыруда катнашу;

2.2.6. Россия Федерациясе икътисады тармакларында һөнәри берләшмәләр төзүдә һәм үстерүдә катнашу;

2.2.7. Карьера үсешенә һәм шәхси үсешкә ирешү өчен, һөнәри белемлелекне үстерүне һәм квалификация дәрәҗәсен күтәрүне дәвам иттерүгә яшьләрнең мотивациясен арттыру;

2.2.8. Россия Федерациясенең белем алу һәм икътисадый процессларында катнашучы гражданнар өчен һөнәри үзбилгеләнү системасын үстерү;

2.2.9. Эшче һөнәрләренең популярлыгын арттыру һәм имиджын күтәрү;

2.2.10. Җитештерү культурасын үстерү;

2.2.11. Үзенчәлекле һөнәрчелек культурасын формалаштыру;

2.2.12. Һөнәри белем бирү системасында белем бирү һәм фәнни-методик эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган оешмаларны алга таба үстерүгә юнәлдерелгән һөнәри белем бирү сәясәтен һәм гомуми якын килүне билгеләү өчен тәкъдимнәр эшләү;

2.2.13. Һөнәр берлеге оешмалары белән хезмәттәшлек итү һәм кеше капиталын үстерү;

2.2.14. Иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен, дәүләт-хосусый партнерлыкны үстерүдә катнашу;

2.2.15. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган Россия һәм чит ил оешмалары белән элемтәләрне ныгыту һәм үстерүгә булышлык күрсәтү;

2.2.16. Россия Федерациясе законнары нигезендә һөнәри һәм федераль дәүләт мәгариф стандартлары проектларын эшләү;

2.2.17. Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә махсуслаштырылган компетенцияләр үзәкләре челтәрен формалаштыру һәм үстерү;

2.2.18. Республика экспертлар реестрын төзү һәм WSR, WSI Россия һәм чит ил экспертлары берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү юлы белән экспертлар берләшмәсен формалаштыру һәм үстерү;

2.2.19. Үзебезнең ил, чит ил һәм халыкара презентацияләр, конференцияләр, семинарлар, симпозиумнар, «түгәрәк өстәлләр» утырышлары, күргәзмәләр, форумнар, һөнәри осталык конкурслары, олимпиадалар һәм әлеге Уставта каралган эшчәнлек максатларына җавап биргән башка массакүләм чаралар оештыру һәм аларны үткәрүдә катнашу;

2.2.20. WSR һәм WSI методикасы буенча һөнәри осталык конкурсларын үткәрү стандартларын һәм регламентларын формалаштыру;

2.2.21. Республика җыелма командасын формалаштыру, әзерләү һәм Россия

һәм халыкара WSR һәм WSI ярышларында катнашуын оештыру;

2.2.22. Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы исеменнән барлык дәрәҗәләрдәге Россия ярышларында катнашуга яки аларны үткәрүгә (WSR илкүләм беренчелеген үткәрүне кертеп) заявка формалаштыру;

2.2.23. Исәпләү техникасы һәм мәгълүмат технологияләре ярдәмендә мәгълүматлар базаларын һәм мәгълүмат ресурсларын төзү һәм куллану;

2.2.24. Җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү;

2.2.25. Нәшер итү һәм агарту эшчәнлеген оештыру, массакүләм мәгълүмат чараларында публикация фәнни, фәнни-популяр һәм методик әдәбият, шулай ук аудио-, видеопродукция чыгару, Автоном оешманың позициясен электрон һәм басма массакүләм мәгълүмат чаралары, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, социаль челтәрләрне кертеп, актив рәвештә чагылдыру;

2.2.26. Реклама эшчәнлеге;

2.2.27. Чаралар әзерләү һәм уткәрү процесслары белән идарә итү буенча мәгълүмат системаларын төзү һәм гамәлгә кертү;

2.2.28. Дәүләт хакимияте һәм жирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итү, уртак чаралар һәм программалар оештыру һәм үткәрү, Автоном оешманың Автоном оешма эшчәнлеге максатларына туры килгән дәүләт һәм муниципаль конкурсларда, программаларда һәм тендерларда катнашуын кертеп;

2.2.29. Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләрне гамәлгә ашыру;

2.2.30. Волонтерлар белән эшләү;

2.2.31. Сәләтле яшьләргә, остазларга, педагогларга, экспертларга һәм галимнәргә аерым казанышлары өчен грант ярдәме күрсәтү;

2.2.32. Автоном оешма эшчәнлеге максатлары нигезендә консультация һәм эксперт хезмәтләре күрсәтү.

2.3. Исемлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган аерым эшчәнлек төрләре белән Автоном оешма махсус рөхсәт (лицензия) алганда гына шөгыльләнергә хокуклы.

## 3. Автоном оешма структурасы һәм аның белән идарә итү

3.1. Автоном оешманың идарә органнары булып түбәндәгеләр тора:

3.1.1. Даими гамәлдә булган коллегиаль орган – Попечительләр советы;

3.1.2. Бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган – генераль директор.

3.2. Гамәлгә куючының махсус компетенциясенә түбәндәге мәсьәләләргә карата карарлар кабул итү кирәк:

3.2.1. Автоном коммерциячел булмаган оешманы фондка үзгәртеп оештыру;

3.2.2. Гамәлгә куючылар составына яңа затлар кабул итү;

3.2.3. Уставны раслау;

3.2.4. Идарә итү тәртибен билгеләү;

3.2.5. Даими гамәлдә булган коллегиаль орган төзү;

3.2.6. Бер генә кеше идарә итә торган башкарма органны билгеләү.

3.3. Автоном оешманың югары коллегиаль идарә органы булып Попечительләр советы тора. Автоном оешманың Попечительләр советы компетенциясенә түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү керә:

3.3.1. Автоном оешма уставына үзгәрешләр кертү һәм уставны яңа редакциядә раслау;

3.3.2. Автоном оешма эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен, Автоном оешма мөлкәтен формалаштыру һәм файдалану принципларын билгеләү;

3.3.3. Попечительләр советы составын үзгәртү;

3.3.4. Автоном оешманың аудиторын раслау һәм аны бүләкләү күләмен билгеләү;

3.3.5. Ревизия комиссиясе әгъзаларын билгеләү;

3.3.6. Автоном оешманың башкарма органын бүләкләү күләмен раслау;

3.3.7. Автоном оешманың еллык хисапларын һәм Автоном оешманың еллык бухгалтерлык хисаплылыгын раслау;

3.3.8. Автоном оешма эшчәнлегенең финанс планын раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү;

3.3.9. Автоном оешманы үзгәртеп оештыру һәм ябу;

3.3.10. «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» Федераль закон нигезендә аларны башкаруда кызыксыну булган алыш-бирешләрне хуплау;

3.3.11. Автоном оешманың филиалларын төзү һәм вәкиллекләрен ачу, филиаллар һәм вәкиллекләр турындагы нигезләмәләрне раслау;

3.3.12. Автоном оешма тарафыннан башка оешмалар төзү һәм аларда катнашу;

3.3.13. Автоном оешманың хуҗалык эшчәнлегенә планлаштырылган һәм планнан тыш ревизияләр һәм аудиторлар тикшерүләре билгеләү;

3.3.14. Автоном оешманың хуҗалык эшчәнлегенең барлык төрләре буенча план һәм хисап документларын соратып алу;

3.3.15. Автоном оешма тарафыннан турыдан-туры яки өлешчә Автоном оешма мөлкәтен сатып алуга, алуга яки алу мөмкинлегенә бәйле булган, Автоном оешманың бер генә кеше идарә итә торган органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә башкарыла торган алыш-бирешнең максималь бәясен билгеләү;

3.3.16. Бәяләре әлеге Уставның 3.3.15 нче пунктчасы нигезендә билгеләнә торган бәядән артык булган алыш-бирешләрне хуплау.

Попечительләр советының махсус компетенциясенә 3.3.1, 3.3.2, 3.3.3, 3.3.4, 3.3.5, 3.3.7, 3.3.9, 3.3.11, 3.3.12 пунктчаларда күрсәтелгән мәсьәләләр керә.

3.4. Автоном оешманың Попечительләр советын Попечительләр советы утырышында аның әгъзалары тарафыннан гади тавышлар күпчелеге нигезендә сайланган рәис җитәкли.

Попечительләр советы составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана. Попечительләр советы составына Татарстан Республикасының тармак министрлыклары вәкилләре һәм ведомстволары керә.

Автоном оешманың Попечительләр советы әгъзалары үзләренең Автоном оешманың Попечительләр советындагы әгъзалыгын Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасы, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы, муниципаль вазыйфа, Рос-

сия Федерациясе дәүләт хезмәте вазыйфасы яки муниципаль хезмәт вазыйфасы белән бергә алып барырга хокуклы.

Попечительләр советы рәисе булмаганда, аның функцияләрен Автоном оешманың Попечительләр советы тарафыннан сайланган Попечительләр советы рәисе урынбасары башкара.

3.5. Автоном оешма хезмәткәрләре булган затлар Автоном оешманың Попечительләр советы әгъзалары гомуми санының өчтән береннән артык тәшкил итә алмый.

3.6. Автоном оешма, Попечительләр советы әгъзасы вәкаләтләрен башкаруга турыдан-туры бәйле чыгымнарны компенсацияләүдән тыш, аларга йөкләнгән функцияләрне башкарган өчен Попечительләр советы әгъзаларына акчалата түләү гамәлгә ашырырга хокуклы түгел.

3.7. Автоном оешманың Попечительләр советы утырышлары кирәк булган саен үткәрелә.

Автоном оешманың Попечительләр советы утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртыдан күбесе катнашса, хокуклы санала. Һәр Попечительләр советы әгъзасы бер тавышка ия.

3.8. Автоном оешманың Попечительләр советы утырышлары Попечительләр советы рәисе, Попечительләр советы әгъзаларының берсе, Автоном оешманың генераль директоры, ревизия комиссиясе инициативасы буенча үткәрелә.

3.9. Автоном оешманың Попечительләр советы карарлары утырышта катнашкан әгъзаларының гади тавышлар күпчелеге нигезендә кабул ителә. Попечительләр советының махсус компетенциясе мәсьәләләре буенча карарлары утырышта катнашкан Попечительләр советы әгъзалары тавышының өчтән икесе нигезендә кабул ителә.

3.10. Автоном оешманың бер генә кеше рәислек итә торган башкарма органы булып генераль директор тора, ул гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Автоном оешманың генераль директоры Автоном оешма эшчәнлеге белән хәзерге вакытта җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра һәм Попечительләр советына хисаплы була. Автоном оешманың Генераль директоры вазыйфага 6 (алты) елга билгеләнә.

Автоном оешманың генераль директоры вәкаләтләре гамәлгә куючы карары белән вакытыннан алда туктатыла ала.

Автоном оешманың генераль директорына вазыйфаларын башкарган өчен эш хакы һәм Автоном оешмада каралган матди бүләкләүнең башка төрләре түләнә.

3.11. Автоном оешманың генераль директоры компетенциясенә әлеге Уставта, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән Автоном оешманың Попечительләр советы компетенциясен тәшкил итмәгән барлык мәсьәләләр керә.

3.12. Автоном оешманың генераль директоры:

3.12.1. Автоном оешма исеменнән ышанычнамәсез эш итә, шартнамәләр төзи һәм үз вәкаләтләре чикләрендә Автоном оешма исеменнән башка алыш-бирешләр башкара һәм алар буенча Автоном оешманың бурычлары үтәлешен тәэмин итә;

3.12.2. Россия һәм чит ил физик һәм юридик затлары, шул исәптән барлык милек рәвешендәге оешмалар, учреждениеләр, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә

органнары белән мөнәсәбәтләрдә, шул исәптән судларда Автоном оешманы ышанычнамәсез тәкъдим итә;

3.12.3. Ышанычнамәләр бирә;

3.12.4. Россия Федерациясе территориясендәге банкларда чит ил валютасында һәм Россия Федерациясе сумнарында хисап счетлары һәм башка счетлар ача;

3.12.5. Приказлар, боерыклар, инструкцияләр һәм Автоном оешма хезмәткәрләре тарафыннан үтәлергә тиешле башка актлар чыгара;

3.12.6. Автоном оешма хезмәткәрләрен, шул исәптән Автоном оешманың структур бүлекчәләре, филиаллары, вәкиллекләре җитәкчеләрен эшкә ала һәм эштән җибәрә; аларга карата дисциплинар җәза һәм бүләкләү чараларын күрә; Автоном оешма хезмәткәрләре арасында вазыйфаларны бүлә, аларның вәкаләтләрен билгели;

3.12.7. Автоном оешманың штат расписаниесен, эш режимын раслый, хезмәт коллективы әгъзаларын социаль тәэмин итү һәм социаль иминиятләштерү мәсьәләләрен хәл итә;

3.12.8. Чараларга мөнәсәбәтле кабул ителгән Попечительләр советы карарларын, норматив хокукый актларын, эш итү документларын, Чараларны үткәрү хокукы булган оешмаларның нигезләмәләрен һәм регламентларын гамәлгә ашыру, шулай ук төзелгән шартнамәләрне үтәү эшен оештыра;

3.12.9. Үзе булмаган вакытта, ләкин иң күбе 30 (утыз) көнгә Автоном оешманың генераль директоры вазыйфаларын башкаручыны билгеләргә хокуклы;

3.12.10. Үз эшчәнлегендә Чаралар әзерләү һәм үткәрүне, инфраструктура объектлары төзелешен җайга сала торган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, халыкара хокукый актлар, норматив хокукый актлар, Чараларны үткәрүгә мөнәсәбәтле төзелгән шартнамәләр һәм килешүләр, шулай ук әлеге Устав нигезендә эш итә.

3.13. Гамәлгә куючы карары буенча Автоном оешманың генераль директоры вәкаләтләре Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә вакытыннан алда туктатыла ала.

3.14. Автоном оешманың финанс-хуҗалык эшчәнлегенә контрольне ревизия комиссиясе гамәлгә ашыра, аның әгъзалары Автоном оешманың Попечительләр советы тарафыннан 6 (алты) елга билгеләнә. Автоном оешманың ревизия комиссиясе вәкаләтләре һәм эшчәнлек тәртибе Попечительләр советы тарафыннан раслана торган ревизия комиссия турындагы нигезләмәдә билгеләнә.

3.15. Ревизия комиссиясе финанс һәм бухгалтерлык хисаплылыгы, матди һәм матди булмаган активларны исәпкә алу, саклау һәм файдалану турындагы документлар, хуҗалык характерындагы оештыру-эш итү актлары, шулай ук Автоном оешманың эчке документларының норматив нигезләмәләре нигезендә Автоном оешма мөлкәтеннән файдалану һәм акчаны тотуның нигезле һәм дөрес булуына кимендә елга бер тапкыр тиешле тикшерүләр үткәрү юлы белән Автоном оешманың финанс-хуҗалык эшчәнлегенә контроль гамәлгә ашыра.

3.16. Ревизия комиссиясе идарә органнарыннан, Автоном оешманың вазыйфаи затларыннан һәм хезмәткәрләреннән финанс, бухгалтерлык, хуҗалык документлары һәм башка документлар, статистика мәгълүматлары, аның функцияләрен башкару өчен кирәкле мәгълүматны һәм аңлатмаларны (шул исәптән язма) таләп итәргә һәм

алырга хокуклы. Таләп ителә торган документлар исемлеге һәм күләме ревизия комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

Ревизия комиссиясенең тиешле вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе, шулай ук идарә органнары, Автоном оешманың вазыйфаи затлары һәм хезмәткәрләре тарафыннан соратылган материалларны бирү тәртибе һәм вакытлары ревизия комиссиясе турындагы нигезләмә белән регламентлаштырыла.

3.17. Ревизия комиссиясе Попечительләр советына тикшерүләр нәтиҗәләрен кертә. Автоном оешманың бер еллык финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре турында бәяләмә хисап финанс елы тәмамланганнан соң бер айдан да соңга калмыйча Попечительләр советына кертелә.

## 4. Автоном оешманың мөлкәте һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеге

4.1. Автоном оешма милкендә яки башка хокукта Россия Федерациясе законнары нигезендә аерымланган мөлкәт, шул исәптән биналар, корылмалар, җир кишәрлекләре, транспорт чаралары, җиһазлар, инвентарь, сумнарда һәм чит ил валютасында акча, кыйммәтле кәгазьләр һәм башка мөлкәт була ала.

4.2. Автоном оешма йөкләмәләре буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләттерү мөмкин булган мөлкәте белән җавап тота.

4.3. Автоном оешма мөлкәтен акчалата һәм башка формаларда формалаштыру чыганаклары булып түбәндәгеләр тора:

Автоном оешманы гамәлгә куючыдан кертемнәр;

юридик һәм физик затларның ирекле мөлкәт кертемнәре һәм иганәләр, грантлар, партнерлар кертемнәре һәм башка иганәчеләр акчасы;

Автоном оешманың әлеге Уставта билгеләнгән эшчәнлек максатларына һәм төрләренә туры килә торган эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашырудан алына торган керемнәр, шул исәптән товарлар, эшләр, хезмәтләр, лицензияләр реализацияләүдән табыш;

акцияләр, облигацияләр, башка кыйммәтле кәгазьләрдән һәм кертемнәрдән алына торган дивидендлар (керемнәр, процентлар);

Автоном оешма милкендә һәм/яки файдалануында булган мөлкәтне файдаланудан һәм сатудан алынган керемнәр;

законда тыелмаган башка кертемнәр.

4.4. Автоном оешма милке булып Автоном оешманың милек хокукындагы, ул сатып алган яки аңа юридик һәм физик затлар тарафыннан бирелгән мөлкәт яки мөлкәт хокуклары тора, акча, акцияләр, кыйммәтле кәгазьләр, интеллектуаль милеккә хокукларны кертеп, ләкин алар белән чикләнмичә.

4.5. Автоном оешма билгеләнеше нигезендә һәм уставта каралган бурычларны һәм максатларны үтәү өчен генә үз мөлкәтенә ия була, аннан файдалана һәм эш итә.

4.6. Автоном оешманы гамәлгә куючы Автоном оешма мөлкәтенә, шул исәптән кертемнәре һәм иганәләре хисабына тупланган өлешенә милек хокукы алмый.

4.7. Генераль директор (аның урынбасарлары), Попечительләр советы әгъзалары, ревизия комиссиясе әгъзалары Автоном оешма мәнфәгатьләрен

якларга тиеш, беренче чиратта Автоном оешманың эшчәнлек максатларына карата, һәм Автоном оешма мөмкинлекләрен әлеге Уставта каралган максатлардан аермалы башка максатларда файдаланмаска яки файдалануны булдырмаска тиеш.

Әлеге пунктның беренче абзацында санап үтелгән затлар Автоном оешмага товарлар кайтартучы (хезмәтләр күрсәтүче) оешмалар яки гражданнар, Автоном оешма житештерә торган товарларның (хезмәтләрнен) эре кулланучылары белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торсалар, әлеге оешмаларның катнашучылары, кредиторлары булсалар яисә әлеге гражданнар белән якын туганлык мөнәсәбәтләрендә торсалар яки әлеге гражданнарның кредиторлары булсалар, тулысынча яки өлешчә Автоном оешма тарафыннан тупланган мөлкәткә ия булсалар яки Автоном оешма мөлкәтеннән файдаланудан, аның белән эш итүдән файда эшли алсалар, теге яки бу гамәлләрне кылуда, шул исәптән алыш-бирешләр башкаруда мәнфәгатьле дип танылалар.

4.8. Әлеге Уставның 4.7 нче пунктында санап үтелгән затлар бер ягы Автоном оешма булган яки булырга җыенган алыш-биреш башкаруда мәнфәгатьле булсалар:

алар алыш-биреш төзү турында карар кабул ителгән мизгелгә кадәр Автоном оешманың Попечительләр советына үзләренең мәнфәгатьләре хакында хәбәр итәргә тиеш;

алыш-бирешне Попечительләр советы хуплаган булырга тиеш.

4.9. Әлеге Уставның 4.7 нче пунктында санап үтелгән затлар тарафыннан бу Уставның 4.8 нче пунктында бәян ителгән таләпләрне бозып башкарылган алыш-бирешне Автоном оешма дәгъвасы нигезендә суд гамәлдән чыккан дип таный ала. Мәнфәгатьле зат Автоном оешмага китергән зыян өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән күләмдә һәм тәртиптә Автоном оешма алдында җавап тота.

4.10. Автоном оешманың тышкы икътисадый эшчәнлеге әлеге Уставта билгеләнгән максатларны тормышка ашыру өчен һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## 5. Автоном оешма Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе

5.1. Әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр Автоном оешманың Попечительләр советы тарафыннан Россия Федерациясе Граждан кодексында, «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» Федераль законда, башка федераль законнарда һәм бу Уставта каралган тәртиптә кабул ителә торган карар нигезендә кертелә.

5.2. Әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр яисә аның яңа редакциясе Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта мәҗбүри рәвештә дәүләт теркәвенә алынырга тиеш һәм теркәлгән вакыттан башлап юридик көчкә ия булалар.

## 6. Автоном оешманы үзгәртеп оештыру һәм ябу

6.1. Автоном оешма Россия Федерациясе Граждан кодексында, «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән нигезләрдә һәм тәртиптә үзгәртеп оештырыла яки ябыла ала.

6.2. Автоном оешма ябылганда кредиторлар таләпләре канәгатьләндерелгәннән соң калган мөлкәт, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнгән булмаса, ул төзелгән максатларга һәм (яки) хәйрия максатларына юнәлдерелә. Автоном оешманы гамәлгә куючы документлары нигезендә аның мөлкәтеннән файдалану мөмкин булмаса, ул дәүләт кеременә җибәрелә.

6.3. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язма керткәннән соң, Автоном оешманы ябу – тәмамланган, ә Автоном оешма гамәлдән чыгарылган дип санала.

## 7. Архив эше. Автоном оешма документларының сакланышы

7.1. Автоном оешма, дәүләт социаль, икътисадый, салым сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында, түбәндәге документларның сакланышын тәэмин итә: идарә, финанс-хуҗалык, шәхси состав буенча һәм Автоном оешма эшчәнлегенә бәйле башка документлар, тарихи кыйммәткә ия материалларны кертеп.

7.2. Автоном оешма үзгәртеп оештырылганда барлык документлар (финанс-хуҗалык, идарә, шәхси состав буенча һ.б.) Россия Федерациясе законнары нигезләмәләре нигезендә хокуклы варисына бирелә.

7.3. Автоном оешма ябылганда даими саклауда булган документлар Автоном оешма урнашкан урын буенча архивка дәүләт саклавына бирелә. Документларны тапшыру һәм тәртипкә китерү архив органнары таләпләре нигезендә Автоном оешма акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## 8. Автоном оешманың җаваплылыгы һәм аның эшчәнлеген контрольдә тоту

8.1. Автоном оешма Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бухгалтерлык һәм статистика хисаплылыгын алып бара. Автоном оешма Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Устав нигезендә үз эшчәнлеге турындагы мәгълүматны дәүләт хакимияте органнарына, Попечительләр советына һәм башка затларга тапшыра.

8.2. Автоном оешма керемнәренең күләме һәм структурасы, шулай ук мөлкәте күләмнәре һәм составы турында, чыгымнары, хезмәткәрләре саны һәм составы хакында, аларга хезмәт өчен түләү турында, Автоном оешма эшчәнлегендә гражданнарның түләүсез хезмәтеннән файдалану хакында мәгълүматлар коммерция сере предметы була алмыйлар.

## 9. Йомгак нигезләмәләр

9.1. Әлеге Устав таләпләре Автоном оешма тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш.

9.2. Әлеге Уставта чагылыш тапмаган барлык мәсьәләләр буенча гамәлгә куючы һәм Автоном оешма Россия Федерациясе законнары нигезләмәләренә таянып эш итә.